РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА БИЗЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
Ул.Центральная, д.46, с.Бизяки, Менделеевский район, Республика Татарстан, 423648

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘЗӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк урам, 46 йорт, Бәзәкә авылы, Менделеевск районы, Татарстан Республикасы,423648

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 13 25.03.2025 ел

“Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 21 ноябрендәге 1 номерлы, “2025 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү турында” 2024 елның 21 ноябрендәге 2 номерлы карарларына үзгәрешләр кертү буенча Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 4 апреле 10.00 сәг. Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2025 елның 4 апреле 13.00 сәг. Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2025 елның 4 апреле 16.00 сәг. Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә
4. Бәзәкә авыл җирлеге җыеннарының барлык этапларын уздыру урыны түбәндәге адреслар буенча:

Беренче этап: Бәзәкә авылы, Яңа урам, 1 й., авыл мәдәният йорты
Икенче этап: Бәзәкә авылы, Үзәк урам, 46 й., административ бина
Өченче этап: Бәзәкә авылы Яр Буе урамы

5. Бәзәкә авылында яшәүчеләр исемлеген җыен этапларына бүлүне территориаль билге буенча түбәндәге тәртиптә башкарырга:

Беренче этап: Яшьләр ур., 1-126 й., Елга аръягы ур.,1-106 й. Яңа ур., 1-36 й
Икенче этап: Үзәк ур., 1-102 й.
Өченче этап: Яр Буе ур. 1-36 й. Дуслык ур., 1-14 й., Бакча ур., 1-11 й., Рифкат Таҗиев ур., 4,7 й. Урман ур., 10 й.

6. “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 21 ноябрендәге 1 номерлы, “2025 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү турында” 2024 елның 21 ноябрендәге

2 номерлы карарларына үзгәрешләр кертергә Сез ризамы?” дигән сорауны расларга һәм чараларны түбәндәгечә бәян итәргә:

1. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (Бәзәкә авылында Бәзәкә елгасы аша күперләрне ремонтлау).

2. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;( вак таш сатып алу, вак ташны тигезләү, Бәзәкә авылындагы юлларны кардан чистарту, узган елларның калган өлешләрен юлларны кардан чистартуга җибәрергә).

3. Урамнарны яктырту җайланмасы (Бәзәкә авылында яктырткычлар сатып алу). Бәзәкә авылында урамнарны яктырту җайланмасы урнаштыру).

4. Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Бәзәкә авылында Беларус 82.1 тракторына фронталь төягеч сатып алу, Беларус 82.1 тракторын тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, (запас частьләр, дизель ягулыгы сатып алу, техник хезмәт күрсәтү), бензин триммерлары сатып алу, үлән чабу, агачлар кисү, территорияне төзекләндерү өчен экскаватор хезмәтләре күрсәтү, балалар спорт мәйданчыгы территориясен төзекләндерү).

5. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чаралары белән тәэмин итү (янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу, янгын сүндерү машинасын буяу өчен буяу сатып алу).

6. Су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; (суга батыру насослары сатып алу).

7. Каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (Бәзәкә авылында рөхсәтсез чүплекләрне бетерү буенча хезмәт күрсәтүләр)

«РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә Бәзәкә авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерергә, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru " Бәзәкә авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга

3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Менделеевск муниципаль районы
Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы ________________ И.И.Кәшәфетдинов
(имза) (имзаның аңлатмасы)